# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында”**
**Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 6 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында” 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2002, № 12, (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 пунктында “районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның Татарстан Республикасы административ-территория бүленешен исәпкә алып” сүзләрен “тиешле районнар, шәһәрләр, шәһәрләрдәге районнар территориясен үз эченә ала торган суд районнары чикләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6 статья. **Җәмәгать судьясы вазыйфасына сайлау тәртибе**

1. Җәмәгать судьялары үз вазыйфаларына Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлана.

2. Җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры тәмамланырга алты айдан да соңга калмыйча, ә җәмәгать судьясы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җәмәгать судьясы вакансиясе ачылган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгать судьясы вакансиясе ачылу турында хәбәр ителә, анда җәмәгать судьясы вазыйфасын дәгъвалаучылардан гаризалар кабул итү вакыты һәм урыны, шулай ук бирелгән гаризаларны карау вакыты һәм урыны күрсәтелә. Яңа сайланган җәмәгать судьясының вәкаләтләре чоры гамәлдәге җәмәгать судьясының вәкаләтләре туктатылган көннән соң килә торган көннән дә иртәрәк булмаган вакыттан башлана.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 28 ноябре
№ 95-ТРЗ